| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2025 ел Баулы шәһәре №170

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 декабрендәге 246 номерлы карары белән расланган, судан файдалану шартнамәләре нигезендә, муниципаль милектәге су объектларын яисә аларның өлешләрен файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 декабрендәге 246 номерлы карары белән расланган, судан файдалану шартнамәләре нигезендә, муниципаль милектәге су объектларын яисә аларның өлешләрен файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Су объектын файдалануга бирү турындагы карар яисә дәлилләп кире кагу документлар алынган көннән алып 15 эш көне эчендә җибәрелә.

Күрсәтелгән гамәлләрне электрон формада башкару өчен техник мөмкинлекләр булмаганда, мондый гамәлләр кәгазьдә 20 эш көненнән артмаган вакытта башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге пунктының беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларга су объектын файдалануга бирү турында кабул ителгән карарны дәүләт су реестрында дәүләт теркәвенә алу чоры кертелә.».

Мөрәҗәгать итүчегә су объектын дәүләт су реестрында дәүләт теркәвенә алу, дәүләт су реестрында карарны теркәү өчен файдалануга бирү турында кабул ителгән

карарны җибәрү, мөрәҗәгать итүчегә су объектын файдалануга бирү турында дәүләт су реестрында теркәлгән карарны җибәрү йә дәүләт теркәвеннән баш тарту өчен кирәкле вакыт муниципаль хезмәт күрсәтү срогына кертелми.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров